Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге Ак-Юл авылында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 20 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенең Ак-Юл авылында гражданнар җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2020 елда, балачактан инвалидлардан, беренче һәм икенче төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылучылардан тыш, Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Ак-Юл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Ак-Юл авылының Лесная урамы буенча юлны ком-чуерташ катнашмасы белән ныгытуга;
- урам яктыртылышының энергия саклау лампаларын сатып алуга, урнаштыруга.

3. Әлеге карарны Димтамак авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, **http://pravo.tatarstan.ru** веб адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Димтамак авыл җирлеге Башлыгы И.А. Сәләмов